ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСКО-ТОЛКИШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ТАЛКЫШЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422961, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
село.Татарский Толкиш, ул.Советская,
дом 2

422961, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Талкышы авылы,
Совет урамы, 2 нче йорт.

тел. 884342 3-32-23, e-mail: Ctp.Ttolk@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 21 2019 елның 24 декабре

Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Кызыл Болгар авылы гражданнар җыенының 2019 елның «12» ноябрендәге 1 номерлы карары, Татар Талкышы авылы гражданнар җыенының 2019 елның «14» ноябрендәге 2 номерлы карары, Кызыл Ялан авылы гражданнар җыенының 2019 елның 15 ноябрендәге 3 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Татар Талкышы авыл
җирлеге башлыгы М.М.Вәлиев

Чистай муниципаль районы
Татар Талкышы авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 21 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш(түләүдән азат ителүче гражданнар категорияләрен күрсәтергә), 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю Тәртибенә кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
__________________________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________
_________________________________________________________________ нигезендә
Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________________
Алучы Банк БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________
ИНН _________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләү билгеләү
__________________________________________________________________________
Җитәкче __________________ ________________________________________
М.П. (имза) (тулы имза)
- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -
хәбәр (хәбәрнамә) № _____
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф. И. атасының исеме __________________________________________
Адрес: __________________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. ______________________________________
(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше ______________________________авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.